РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 17 августы № 33

Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең коррупциячел хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турында» 2012 елның 20 декабрендәге 42 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2012 елның 20 декабрендәге 42 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең коррупциячел хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.15.6 пунктын «, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләре белән тулыландырырга;

1.15.7 пунктын «, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләре белән тулыландырырга;

2.4.1 пунктын «, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләре белән тулыландырырга;

2.4.2 пунктында «дөрес булмаган яки» сүзләрен төшереп калдырырга, «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләре белән тулыландырырга;

түбәндәге эчтәлектәге 2.7 пункты белән тулыландырырга:

«2.7. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан 2.4.2 пунктында күрсәтелгән күрәләтә дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

түбәндәге эчтәлектәге 2.8 пункты белән тулыландырырга:

«2.8. Муниципаль хезмәткәр чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне һәм, коррупциягә каршы тору максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен, әгәр мондый чикләүләр, тыюлар һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган шартлар нәтиҗәсе буларак танылган очракта, җаваплылыктан азат ителә.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры вазыйфаларын башкаручы,
Мэр урынбасары

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

М.В. Камелина